РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Бирючевского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

ул. Школьная, д. 2, Азнакаевский район,
д.Бирючевка, 423307,
тел./факс (885592)61-8-81
E-mail: Bir.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Бирючевка авыл җирлеге
башкарма комитеты

Школьная ур., 2 йорт, Азнакай районы,
Бирючевка авылы, 423307
тел./факс (885592)61-8-81
E-mail: Bir.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от «28» января 2025г.** **№20**

2025 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Бирючевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенең иң чик күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында»гы 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында»гы Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 23 гыйнварындагы 33 номерлы «2025 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында»гы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бирючевка авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Бирючевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә, 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә, 2025 елның 01 февраленнән күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә 9 165,37 (тугыз мең йөз алтмыш биш сум утыз җиде тиен) күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык З.Г.Солтанова

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бирючевка авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына №1 нче кушымта
«28» январь 2025 № 20

2025 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Бирючевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясенең чик күләме

| **№** | **Хезмәт күрсәтүнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүнең бәясе, сум.** |
|---|---|---|
| 1 | Мәетне җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4 070,37 |
| 2 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 1 800,00 |
| 3 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 295,00 |
| **4** | **Барлыгы** | **9 165,37** |

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бирючевка авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына №2 нче кушымта
«28» январь 2025 № 20

2025 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Бирючевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясенең чик күләме

| № | Хезмәт күрсәтүнең атамасы | Хезмәт күрсәтүнең бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | Кәфенләү | 1 500,00 |
| 2 | Мәетне җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 570,37 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 1 800,00 |
| 4 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 295,00 |
| **5** | **Барлыгы** | **9 165,37** |